**Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының «индивидуаль торак төзелеше өчен гражданнар милкенә (арендага) җир кишәрлеге бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 23 июлендәге 541 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының 23.07.2019 № 541 карары белән расланган индивидуаль торак төзелеше өчен гражданнар милкенә (арендага) җир кишәрлеге бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертергә:

1) 2 бүлегендәге 2.9 пунктының 3.1 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

2) 2 бүлегенең 2.9 пунктындагы 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җир кишәрлеге бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан, моңа мондый җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, андагы урыннар, төгәлләнмәгән төзелеш объекты милекчесе яисә мондый җир кишәрлегенең Хокук иясе җир кишәрлеге бирү турындагы гариза белән мөрәҗәгать иткән очраклар керми";

3) 2 бүлегенең 2.9 пунктындагы 13 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«гаризада күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата Россия Федерациясе Җир Кодексының 39.18 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлеге бирү турында хәбәр басылып чыкты һәм урнаштырылды»;

4) 3 бүлекнең исеменә, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

"Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны башкару тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең гомуми билгеләр белән берләштерелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә, шул исәптән алар сорап мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә карата күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтү тәртибен үз эченә алган вариантлары»;

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.А. Гасыймов**